МИНИСТЕРСТВО ЭКОНОМИКИ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ИКЪТИСАД МИНИСТРЛЫГЫ

ПРИКАЗ

БОЕРЫК

Казан шәһ.

**Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының «Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгында дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс уздыру турындагы нигезләмәне раслау турында» 2011 елның 12 июлендә имзаланган 158 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгында дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс уздыру турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының «Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгында дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс уздыру турындагы нигезләмәне раслау турында» (алга таба – Нигезләмә) 2011 елның 12 июлендә имзаланган 158 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгында дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс уздыру турындагы нигезләмәне Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясендә дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс уздыру турында» 2005 елның 1 февралендә кабул ителгән 112нче Указына яраклаштыру максатында **боерам:**

1.Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3нче пунктның «г» подпунктында «конкурс нигезендә формалаштырылган кадрлар резервында торган» сүзләрен «граждан хезмәтендә кадрлар резервына кертелгән» сүзләре белән алмаштырырга»;

7нче пунктның «е» подпунктын түбәндәге редакциядә бирергә:
«е) «Россия Федерациясендә дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендә кабул ителгән 79-ФЗ номерлы Федераль законда, башка федераль законнарда, Россия Федерациясе Президенты указларында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте Карарларында каралган башка документлар»;

18нче пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бирергә: «Конкурс комиссиясе составына Министр һәм (яки) ул вәкаләтләр биргән граждан хезмәткәрләре (шул исәптән кадрлар бүлегеннән, юридик бүлектән һәм граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс уздырыла торган структур подразделениедән),

дәүләт хезмәте белән идарә итүнең Татарстан Республикасы дәүләт органы - Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты (алга таба - Департамент) вәкиле, шулай ук граждан хезмәте белән бәйле сораулар буенча белгечләр – персональ мәгълүматлары күрсәтелмәгән бәйсез экспертлар сыйфатында (алга таба – бәйсез экспертлар) Министр гарызнамәсе буенча Департамент тарафыннан чакырылган фәнни һәм белем бирү учреждениеләре, башка оешма вәкилләре керә.
Конкурс комиссиясе составына шулай ук Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының 2010 елның 8 декабрендәге 368нче боерыгы белән оештырылган Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының иҗтимагый советы вәкиләре дә кертелә.

Әлеге вәкилләрнең һәм бәйсез экспертларның гомуми саны конкурс комиссиясе әгъзаларының гомуми санының дүрттән береннән дә ким булмаска тиеш»;

20нче пунктның өченче абзацында «рәисен» сүзен «утырышта рәислек итүчене» сүзләре белән алыштырырга.

2. Кадрлар бүлеге башлыгына (В.Р.Садыйкова) әлеге боерыкка Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында дәүләт теркәве уздырырга.

3. Әлеге боерыкның үтәлешенә контрольлек итүне үз өстемдә калдырам.

**Министр** **М.Р.Шаһиәхмәтов**